**ГЛАВА НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422627 , с.Никольское ,**
**ул. Центральная , д 35**
**тел: 4-31-44**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**422627 Сапуголи авылы,**
**Эзэк урамы , 35 нчы йорт,**
**Тел : 4-31-44**

---

2024елның 28 октябре 2 номер

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең Сапуголи авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

2024 елның 9 ноябрендә 10.00тән 13.00 сәгатькә кадәр, 2024 елның 16 ноябрендә 10.00тә Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Никольский авыл җирлеге, Сапуголи авылы территориясе өлешендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Сапуголи торак пункты Южная, Лесная урамнары территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

2. «ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Никольский авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында рәсми кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Никольский
авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы__________________ А.Н.Пашагин